ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ АГРЫЗСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ул. Гагарина, д.13, г. Агрыз, 422230

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ӘГЕРҖЕ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

Гагарин ур.,13, Әгерҗе шәһәре, 422230

Тел.: (85551) 2-22-46; Факс: 2-30-61; E-mail: isp.agryz@tatar.ru; www. agryz.tatarstan.ru

**РАСПОРЯЖЕНИЕ** **КҮРСӘТМӘ**

«16 » февраль 2022 ел № 26-р

Технологик тоташтыру тәртибе турында халыкка мәгълүмат бирү, гаризалар җыю, газификация килешүләрен үз вакытында төзү һәм үтәү мәсьәләләре буенча «Газпром трансгаз Казан» ЖЧҖ белән үзара хезмәттәшлек итүдә җаваплы затны билгеләү турында

Татарстан Республикасында эпидемиологик вәзгыять мәсьәләләре һәм яңа коронавирус инфекциясе таралуны булдырмау чаралары буенча Татарстан Республикасы Президенты Р.Н. Миңнеханов рәислегендә видеоконференция режимында республика киңәшмәсе беркетмәсенең 2 нче пунктын үтәү йөзеннән, торак фондын һәм социаль билгеләнештәге объектларны төзү һәм капиталь ремонтлау буенча республика программаларын гамәлгә ашыру, ТКХны модернизацияләү өлкәсендә программалар, торак-коммуналь хуҗалыкта күрсәтелә торган хезмәтләрнең сыйфатын яхшырту, «Безнең ишегалды» программасын гамәлгә ашыру, Татарстан Республикасы территориясендә халыкны газификацияләү һәм газ белән тәэмин итүнең социаль юнәлешле һәм икътисадый нәтиҗәле системасын кертү турында Россия Федерациясе Президентының 2022 елның 03 февралендәге АП-12-29 йөкләмәләрен үтәү максатларында, «Алабуга» ЭПУ ның 2022 елның 11 февралендәге Исх-109-04-142 номерлы «Мәгълүмат бирү турында» хаты нигезендә:

1. Технологик тоташтыру тәртибе турында халыкка мәгълүмат бирү, гаризалар җыю, газификация килешүләрен үз вакытында төзү һәм үтәү мәсьәләләре буенча «Газпром трансгаз Казан» ЖЧҖ белән үзара хезмәттәшлек итүдә җаваплы зат итеп - Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Башкарма комитетының төзелеш, архитектура һәм шәһәр төзелеше бүлеге башлыгы Хаҗиева Лилия Ренат кызын билгеләргә.
2. Җаваплы вазыйфаи затка гамәлдәге законнар таләпләре нигезендә эш оештырырга.
3. Әлеге карарны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталы составында Әгерҗе муниципаль районының рәсми сайтында (https://agryz.tatarstan.ru) урнаштырырга.
4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз өстемә алам.

**Җитәкчесе** **А.Э. Акбашев**